**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**2016 елның «14» ноябре** **№ 60**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Н.М. Тухтаркинның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең территориаль планлаштыру документы проекты турында мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен исәпкә алып, 2016 елның 24 октябрендә халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗә 2016 елның 04 ноябре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына таянып, «Татарстан Республикасында яңа төзелгән җирлекләрдә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2005 елның 12 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авылы муниципаль берәмлегенең генераль планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитетына

2.1. Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 5 өлеше таләпләренә туры китереп халыкка җиткерергә һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

2.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планын гамәлгә ашыруга бәйле чараларны тормышка ашырырга.

3. Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Тухтаркин Н.Мга.әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

**Өтәшкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **Н.М. Тухтаркин**